2025 елда гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Бакырчы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар

13 .11. 2024 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 13 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде. «сез 2025 елда һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы?, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бакырчы авыл җирлегенең Бакырчы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, атап әйткәндә: ата-аналарыннан, ирләреннән йә хатыннарыннан, балигъ булган балаларыннан тыш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү түбәндәге эшләрне башкару буенча:

- Газизҗан урамындагы 1 нче йорттан алып Такташ урамындагы 1 нче йортка кадәр Бакырчы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш, ком сатып алу, нигезне әзерләү, ташу, салу, эш өчен түләү)?

“КАРШЫ” “РИЗА”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 235 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 130 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«риза» позициясе өчен гражданнар җыенында 130 катнашучы тавыш бирде;

«каршы» позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бакырчы авыл җирлегенең Бакырчы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бакырчы авыл җирлегенең Бакырчы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасындагы студентлардан, балачактан инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр) тыш, 2025 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы?, мобилизацияләнгәннәр, ирекләләр) һәм аларның гаилә әгъзалары, атап әйткәндә: ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балаларны һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- Газизҗан урамындагы 1 нче йорттан алып Такташ урамындагы 1 нче йортка кадәр Бакырчы торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия

булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш, ком сатып алу, нигезне әзерләү, ташу, салу, эш өчен түләү)?»

“КАРШЫ” «РИЗА”

кабул ителгән.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бакырчы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

Җитәкче И.М.Шәмсетдинов